**ПРОЕКТ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАР №_____**

__ чакырылыш ___ утырышы Уруссу штп «___» ______ 2022 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы "Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2022елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә , Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 11 номерлы Ютазы район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1 пунктында «11 958» санын «12 688» санына алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль районның контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең әлеге карар белән расланган хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларында:

1 бүлекнең 6 пунктында «7,71» санын «10,36» санына, «6,72» санын «9,26» санына алмаштырырга;

2 бүлекнең 6 пунктында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән карар нигезләмәсенә 1 нче һәм 2 нче номерлы кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Ютазы муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек алар кабул иткән хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә электрон массакүләм мәгълүмат чарасында рәсми бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://yutazy.ru (челтәр басмасы буларак теркәлү: ЭЛ № ФС 77 - 47613 от 07.12.2011), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы районы
Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең Ютазы район Советының 2018 елның 25 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәгә 1 нче номерлы кушымта ( «___»______20___ел №_____ редакциясендә)

## Ютазы муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасарының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органы рәисенең акчалата түләү күләмнәре

| Вазифалар исемнәре | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 нче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 33 592 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 30 233 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 30 233 |

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләр рәисләренең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә 2 нче номерлы кушымта ( «___»______20___ел №_____редакциясендә )

## Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының акчалата түләү күләмнәре

| Вазифалар исемнәре | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә | | | |
| | 9нчы төркем | 10нчы төркем | 11нче төркем | 12нче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 608 | 20 688 | 19 039 | 17 390 |